**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Нижнекамский городской**
**С О В Е Т**

423570, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
факс (8555) 42-46-48, 42-42-66

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама шәһәр**
**С О В Е Т Ы**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 42-46-48, 42-42-66

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 7** **2016 елның 16 феврале**

**Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәренең**
**Алан авылын бетерү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законының 13.1 статьясы, 07.12.2005 елдагы 116-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында” Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 7 пункты буенча, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Алан авылын бетерергә.
2. Әлеге карарны 2005 елның 31 гыйнварындагы 31-ТРЗ номерлы "Түбән Кама муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү өчен Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советына җибәрергә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин